ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# "Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында" 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш), Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә "Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында" Федераль законда һәм әлеге Законда каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга, шул исәптән гражданнарны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танырга, социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзергә вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органын (алга таба – Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтле органы) билгеләү;";

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

"3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтле органы үз карамагындагы оешмаларга, кирәк булган очракта, бер яисә берничә муниципаль берәмлек территориясендә гражданнарны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү вәкаләтләрен (алга таба – вәкаләтле оешмалар) бирә.";

3) 7 статьяның 2 өлешендә “Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге вәкаләтле органы” сүзләреннән соң “яисә вәкаләтле оешма” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 16 март
№ 12-ТРЗ